**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru

ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
28.04.2020

**КАРАР**
№ 216

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуны җайга салуны даими рәвештә гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында пассажир йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы 2018 елның 10 декабрендәге 698 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуны җайга салуны даими рәвештә гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында пассажир йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы 2018 елның 10 декабрендәге 698 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2 нче кушымтасының 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «1.1. Килешү предметы булып Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы территориясендә шәһәр яны автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру белән бәйле эшләрне башкаруга Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тора».

1.2. Карарга кушымтаның 2.6 пунктының 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «- субсидия алучылар - юридик затлар үзгәртеп кору, эшен туктату процессында булырга тиеш түгел, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган, ә субсидия алучылар - шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген индивидуаль эшкуар буларак туктатырга тиеш түгел;».

2. Карарның 2 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

3. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында урнаштырырга» (PRAVO.TATARSTAN.RU).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.И. Хисамовага йөкләргә.

**Тәтеш муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**җитәкчесе** **А.Б. Семенычев**

Тәтеш муниципаль районы
башкарма комитетының
2020 елның 28 апрелендәгә
216 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы территориясендә муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуны даими гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында пассажир йөртүчеләргә субсидияләр бирү комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Семенычев А.Б. | Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| Хисамова И.И. | Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| **Комиссия әгъзалары** | |
| Ахметшин А.Ф. | Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| Богданов А.А. | Тәтеш муниципаль районы финанс-бюджет палатасы рәисе; |
| Гасимова Ю.Г. | Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының социаль-икътисади һәм территориаль үсеш бүлеге начальнигы |